**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Исполнительный комитет
Татарско-Шуганского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района

ул. Советская, д. 41в, село Татарский Шуган,
Азнакаевского муниципального района, 423327
Тел. (факс) (85592) 36-1-41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы Татар
Шуган авыл җирлеге башкарма
комитеты

Совет урамы, 41в, Татар Шуган авылы
Азнакай муниципаль районы, 423327
Тел. (факс) (85592) 36-1-41

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» сентябрь 2019 ел №42

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Татар Шуган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, карар чыгарам:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Сез 2020 елда Татар Шуган авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан түләүне киметеп, аны 150 сум (50%) күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Татар Шуган авылында Совет, Х.Такташ, Яна урамнарнын юлларына щебенка җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү)

- Татар Шуган авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;

- Татар Шуган авылында җәй көне территорияне чабу;

- Татар Шуган авылында коры агачларны, куакларны кисү;

- Татар Шуган авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

- Татар Шуган авылында һәлак булган сугышчылар һәйкәлләрен ремонтлау (коймалар урнаштыру, буяу, агарту, эшләр өчен килешү буенча түләү);

-Татар Шуганы авылында «Халыкара өлкәннәр көне», «Сабантуй» бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру;

- Татар Шуган авылында  урам күрсәткечләрен ике телдә ясау һәм урнаштыру.

ӘЙЕ　　　　　　　　　　　　　　　　ЮК

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар  аша халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Татар Шуган авылы, Совет урамы, 41в йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Башлык　　　　　　　　　Г.З.Мияссарова